| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.02.2026 Балык Бистәсе штп. № 31пи

Физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын (шул исәптән әһәмиятле халыкара рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын) уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында

Физкультура-савыктыру һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән физкультура-савыктыру, спорт һәм тренировка чараларын уздыруга чыгымнар нормаларын җайга салу максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы физкультура чараларының һәм спорт чараларының календарь планына кертелгән рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын (шул исәптән халыкара рәсми физкультура чараларының һәм спорт чараларын) уздыруга чыгымнар нормаларын раслау турында» 02.12.2025 №1031карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Кушымталарны расларга:

рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларны туклану белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын;

рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормаларын;

рәсми физкультура чараларына һәм спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләү чыгымнары нормаларын. .

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинга йөкләргә.

Җитәкче Д.А. Сатдинов

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.02.2026 №31пи
карары белән расланган

## Рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларны туклану белән тәэмин итү чыгымнары нормалары

| № п/п | Спорт чараларының атамалары | Бер кешегә көнгә чыгымнар нормасы, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Региональ һәм муниципальара физкультура чаралары һәм спорт чаралары | 700 кадәр |
| 2. | Бөтенроссия физкультура чаралары һәм спорт чаралары | 1 300 кадәр |
| 3. | Олимпия уеннарына карамаган, паралимпиягә карамаган һәм сурдлимпиягә карамаган спорт төрләре буенча халыкара спорт чаралары | 1 300 кадәр |
| 4. | Олимпия, паралимпия һәм сурдлимпия спорт төрләре буенча халыкара спорт чаралары | 1 300 кадәр |

Искәрмә:

Рәсми физкультура чараларын һәм спорт чараларын үткәргәндә катнашучыларны туклану белән тәэмин итүгә нормативтан тыш чыгымнарны каплау оешмаларның эшкуарлык һәм керем китерә торган башка эшчәнлектән алган акчалары исәбеннән, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.02.2026 №31пи
карары белән расланган

Рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларны яшәү белән тәэмин итү чыгымнары нормалары

| №<br>п/п | Яшәү өчен торак пунктларның категорияләре атамалары | Бер кеше-көннең бәясе, сум |
|---|---|---|
| 1. | Мәскәү, Санкт-Петербург, Сочи | 2 500 кадәр |
| 2. | Россия Федерациясе субъектларының административ үзәкләре;<br>Ерак Төньяк территориясенә кертелгән шәһәрләр, торак пунктлар | 2 500 кадәр |
| 3. | Россия Федерациясе территориясендәге башка шәһәрләр һәм торак пунктлар | 2 000 кадәр |

Искәрмә: Рәсми физкультура чараларында һәм спорт чараларында катнашучыларны яшәү белән тәэмин итүгә нормативтан тыш чыгымнарны каплау оешмаларның эшкуарлык һәм башка керем китерә торган эшчәнлегеннән алынган акчалар исәбеннән, шул исәптән түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Балык
Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
03.02.2026 №31пи
карары белән расланган

Рәсми физкультура чараларына һәм спорт чараларына хезмәт күрсәткән өчен спорт судьяларына түләү чыгымнары нормалары

| № п/п | Судья вазыйфаларының аталышы | Судьялар категорияләрен исәпкә алып түләүләр күләме, сумнар | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | МК, ВК | 1К | 2К | 3К/Ю/С | категориясез |
| 1. | Баш судья | 1 490 | 1 096 | - | - | - |
| 2. | Баш судья-секретарь | 1 490 | 1 096 | - | - | - |
| 3. | Баш судья, баш судья-секретарь урынбасары Баш судья-секретарь | 1 100 | 918 | 733 | - | - |
| 4. | Судьялар | 998 | 796 | 679 | 624 | 530 |
| Командалы уен спорт төрләре | | | | | | |
| 5. | Уенның баш судьясы | 870 | 696 | - | - | - |
| 6. | Уенның баш судьясы ярдәмчесе | 635 | 547 | - | - | - |
| 7. | Инспектор (техник делегат, комиссар) | 679 | - | - | - | - |
| 8. | Судьялар ( бригада составында) | 515 | 484 | 445 | 406 | 359 |

Шартлы билгеләр:
МК-халыкара категорияле спорт судьясы;
ВК-Бөтенроссия категорияле спорт судьясы;
1К - беренче категорияле спорт судьясы;
2К - икенче категорияле спорт судьясы;
3К - өченче категорияле спорт судьясы;
Ю/С - яшь спорт судьясы.